МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОСУДАРСТВЕННОЕ АВТОНОМНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ИНСТИТУТ РАЗВИТИЯ ОБРАЗОВАНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТУГАН ТЕЛ һӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ» УКУ ПРЕДМЕТЫ ӨЧЕН ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР (ЛЕКСИКОЛОГИЯ)

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ
БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

«ТУГАН ТЕЛ һӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ» УКУ ПРЕДМЕТЫ ӨЧЕН ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР (ЛЕКСИКОЛОГИЯ)

Казан
2023

ББК 74.202
Т 81

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп, ТРМҮИ гыйльми советы карары нигезендә басыла
Гомуми редакция: Нугуманова Л.Н., ТРМҮИ ректоры, педагогика фәннәре докторы; Шәмсетдинова Л.П., ТРМҮИ фәнни һәм инновацион эшчәнлек буенча проректоры, химия фәннәре кандидаты

Фәнни мөхәррир: Шәмсетдинова Р.Р., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент.

Рецензент: Җамалетдинова З.И., ТР МҮИ мәктәпкәчә һәм башлангыч гомуми белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты.

Төзүчеләр: Р.Ф. Фәттахова, ТР Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Р.Р Шәмсетдинова, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент; Гыйлаҗева Л.Г., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Г.М. Шакирова татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Г.В. Хадиева, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы, Ә.Р. Вahапова., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

«ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ» УКУ ПРЕДМЕТЫ ӨЧЕН ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР (ЛЕКСИКОЛОГИЯ) / төз.: Фәттахова Р.Ф., һ.б.— Казан: ТРМҮИ, 2023 — 44 б.

Методик ярдәмлек белем бирү оешмаларында эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, мәктәп җитәкчеләренә, милли мәгариф хезмәткәрләренә тәкъдим ителә. Хезмәттә яңартылган федераль дәүләт стандартлары шартларында татар телен укыту буенча методик тәкъдимнәр бирелә, «Туган тел һәм туган тел әдәбияты» өлкәсен укытуныңтөп дидактик юнәлешләре һәм принцлары күрсәтелә, сөйләм компетенциясен үстерү һәм бу юнәлештә дидактик материалларны куллану үзенчәлекләре ачыклана, лексикология буенча дидактик бирем, күнегү, уен, тест үрнәкләре тәкъдим ителә.

©ТРМҮИ, 2023

ДИДАКТИКА һӘМ ЛИНГВОДИДАКТИКА

Дидактика — педагогиканың аерым бүлеге, мәгариф теориясе һәм укыту технологияләре турында фән. Дидактиканың өйрәнү предметы булып белем бирү эчтәлегенең закончалыклары, принциплары, максатлары, фәнни нигезләре, формалары, укыту чаралары тора.

Дидактиканың төп бурычлары: 1)белем бирү закончалыкларын ачыклау һәм аларны белем бирү максатларына ирешү өчен куллану; 2)заманча белем бирү процессын анализлау һәм тасвирлау; 3)укытуның теоретик модельләрен эшләү һәм аларны апробацияләү; 4)белем бирү процессын оештыруның нәтиҗәле методларын һәм формаларын булдыру; 5)дәреснең методик проблемаларын анализлау һәм гомумиләштерү; 6)укучыларның өлгерешен тикшерү һәм бәяләү формаларын анализлау.

Лингводидактика — дидактиканың бер бүлекчәсе, телгә өйрәтүнең гомуми теориясе. Бу өлкә телләргә өйрәтүнең гомуми закончалыкларын тикшерә, дидактик максатларга бәйле рәвештә, билгеле бер телгә өйрәтү методларын һәм чараларын эшли, монолингвизм (бертеллелек) яки телне үзләштерүгә билингвизм (икетеллелек) йогынтысын өйрәнә.

Россия Федерациясе халыкларының туган телләрен укыту өлкәсендә «лингводидактика» һәм «методика» терминнары бүленеше нигезендә без ике үзара бәйләнешле юнәлеш турында сөйли алабыз:

1)гомумтеоретик мәсьәләләр белән шөгыльләнә торган лингводактика (белем бирү эчтәлеге, максатлары, бурычлары, методлары, чаралары, процессы, тикшеренү методлары, укытучы һөнәренә карата таләпләр); 2)белем бирүнең конкрет шартларында конкрет туган телләргә һәм сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәтү методикасы, белем бирү процессын оештыру.

Белем бирүдә дидактик юнәлеш — методиканың төп категориясе, ул укыту стратегиясен һәм укыту методын сайлап алу ысулын билгели.

«ТУГАН ТЕЛ һӘМ ТУГАН ТЕЛДӘ ӘДӘБИЯТ» ӨЛКӘСЕН УКЫТУНЫҢ ТӨП ДИДАКТИК ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Федераль дәүләт стандартларының гомуми белем бирүнең методологик нигезен шул ук *системалы-эшчәнлекле юнәлеш* тәшкил итә. Әлеге юнәлешне куллану белем һәм күнекмәләр булдыру гына түгел, аны куллана белү, укучының шәхес үсешен, рухи-әхлакый һәм социаль тәҗрибәгә ия булуын тәэмин итүне күз алдында тота.

Системалы-эшчәнлекле юнәлеш укучы шәхесенең рухи потенциалын үстерүгә, иҗади сәләтләрен ачуга, уку предметына кызыксыну уятуга корылган. Димәк, укыту процессында бу юнәлешне куллану укучыларның белем алу эшчәнлеген актив, төрле яклы, максималь дәрәҗәдә мөстәкыйль, тиешле нәтиҗәгә ирешерлек итеп планлаштыру һәм оештыруны күздә тота. Укытучы дәрестә яңа белемнәрне әзер килеш бирми, укучыларның белемнәрне «ачу» эшчәнлеген оештыра. Бу иҗади процесста укучының белем дәрәҗәсе арту, фикерләү сәләте үсү, индивидуаль шәхси үзенчәлекләре камилләшү белән берлектә аның тормышта үзенең урынын табарга мөмкинлек бирәчәк эшчәнлек сыйфатлары да барлыкка килә (ягъни УУГ формалаша): максат кую, максатка ирешү юлларын мөстәкыйль табу, эшне планлаштыру һәм оештыру, фикерли, анализлый, чагыштыра һәм гомумиләштерә белү, эш нәтиҗәләрен адекват бәяли белү, эшнең барышы һәм нәтиҗәсе өчен җаваплылык сизү, командада эшли алу, үз фикерен әйтә һәм дәлилли белү һ.б.

Системалы-эшлекле юнәлештә төп урынны «эшчәнлек» төшенчәсе алып тора.

Балаларга тәкъдим ителә торган биремнәр иҗади эш таләп итәләр: «уйлап табырга», «төзергә», «сайлап алырга», «ясап куярга», «тасвирларга».

Педагог дәрес эшчәнлеген оештыручы: дидактик материал әзерли, укучылар белән төрле формадагы хезмәттәшлекне оештыра, алар эшчәнлеге нәтиҗәләре турында фикер алышуда катнаша, сораулар бирә, үзконтроль һәм үзбәя бирү өчен шартлар тудыра.

Әлеге юнәлеш белем бирүдә традицион методларны инкяр итми, бары шул җирлектә яңача белем бирү максатларын тормышка ашыру юнәлешендә яңа эшчәнлек төрләрен, укыту технологияләрен куллануны алга чыгара.

Системалы-эшчәнлекле юнәлешне гамәлгә ашыру түбәндәге ысулларга таяна: актив; интерактив; тикшеренү; проект алымнары.

1.Актив укыту методлары — укыту процессын оештыруга юнәлдерелгән һәм белем алучыларны танып белү эшчәнлеге барышында уку материалын мөстәкыйль, инициативалы һәм иҗади үзләштерүгә мотивлаштыра торган шартлар тудыра торган педагогик гамәлләр һәм алымнар җыелмасы.

2.Интерактив укыту — актив белем бирү методы. Бу методны башкача «диалоглы укыту» дип тә атыйлар.

3.Тикшеренү — укучыларга танып белү бурычы күрсәтелә, алар дөрес дип табылган алымнарны сайлап, аны мөстәкыйль рәвештә хәл итәләр. Әлеге метод

укучыларда белемнәрне иҗади куллану сәләтен үстерүне тәэмин итә.

4.Проект методы — танып белү эшчәнлеген оештыруның махсус формасы. Ул конкрет һәм фаразлана торган максатларны күздә тота.

Шәхескә юнәлешле укыту — ул бала шәхесенә тирән хөрмәт булу, аның индивидуаль үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алу, тәрбия процессының аңлы, итеп оештырудан гыйбарәт. Белем бирү процессында укучы шәхесенең үсеше, белем алу мотивы һәм тормыш мәгънәсе алгы планга чыга. Әлеге юнәлешне куллануның максаты — балага тормышта үз-үзен табарга мөмкинлек бирү, әхлакый яктан камилләштерү, әйләнә-тирә шартларга җайлашу, үз-үзен яклый алырга өйрәтү.

Компетентлылык юнәлеше. Әлеге юнәлеш нигезендә белем бирүнең максаты — белем, күнекмәләр җыелмасы булдыру гына түгел, ә компетенцияләр җыелмасы — укучыларның үзләре алдында барлыкка килә торган гамәли бурычларны мөстәкыйль рәвештә хәл итү сәләте булдыру. Әлеге алым кысаларында «компетенция» һәм «компетентлык» терминнары дифференциациясен (аермасын) белү мөһим. Компетенция — уку процессында алынган белем, күнекмәләр, эшчәнлек ысуллары җыелмасы. Компетентлык — билгеле компетенцияләргә ия булу. Хәзерге вакытта укучы тел һәм әдәбият өйрәнү аша лингвистик, коммуникатив, мәдәни (лингвомәдәни, этномәдәни, социомәдәни), уку, әдәби, иҗади компетенцияләргә ия булырга тиеш.

Шәхси эшчәнлекле юнәлеш. Белем бирү процессында түбәндә шартлар булдыру күз алдында тотыла:

1) укучыларның белем алудагы мөстәкыйльлекләренә зур игътибар бирелә, бу исә дәреснең максатларын һәм бурычларын билгеләүдә, алар өчен уңышлы булган эш алымнарын сайлауда чагыла;

2) укучыларның төрле өлкәләрдәге булган белемнәренә таяну һәм дәрес барышында алардан файдалану;

3) укучыларның социаль-мәдәни үзенчәлекләрен һәм аларның яшәү рәвешен исәпкә алу;

4) укучыларның эмоциональ халәтен һәм аларның әхлакый кыйммәтләргә мөнәсәбәтләрен исәпкә алу;

5) укытучыны дәресне оештыручы, консультант, ярдәмче, киңәшче булуына өстенлек бирү;

7) дәрестә аутентик материаллардан файдалану (уку-өйрәнү өчен төзелмәгән, ләкин уку процессында өстәмә материал итеп кулланып була торган материаллар: фәнни-популяр телетапшырулар, мультфильмнар, интервью, реклама, хатлар, җырлар, шигырьләр һ.б.).

Коммуникатив-эшчәнлекле юнәлеш.

Төп критерийлар:

1) телгә өйрәтүдә сөйләшергә өйрәтү максаты беренчел булу — укучыларда коммуникатив компетенцияләр формалаштыру;

2) материалны сайлап алуда һәм оештыруда функциональлек. Телнең функциональ ягына басым ясала. Аралашуга корылган эшлекле биремнәрдә төрле тел берәмлекләре үзләштерелә: укучы сорау бирә, фикерне раслый, инкяр итә, шикләнә, риза була, әңгәмәдәшен ниндидер эшкә чакыра һ.б. Һәрбер очракта

билгеле бер грамматик форманы үзләштерү һәм нығыту тормышка ашырыла;

3) ситуативлык. Укыту материалын сайлаганда һәм укыту процессын оештырганда укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм кызыксыну даирәләрен искә алып проблемалы ситуацияләрне коммуникатив хәл итүгә максималь игътибар бирелә. Укучылар төрле рольләргә кереп, ситуацияле уеннарда катнашалар;

4) аралашу күнекмәләрен формалаштыруга ярдәм итә торган коммуникатив биремнәрне куллану;

5) укучыларның телгә ихтыяҗларын һәм аларның индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, укыту процессын индивидуальләштерү.

Мәдәни юнәлеш буенча тел мәдәни үсеш продукты буларак өйрәнелә. Тел мәдәният өлкәсенең милли үзаңны формалаштыра торган состав өлеше буларак карала. Бу күбесенчә, мәдәни юнәлешле текстлардан (әдәби әсәрләр, фольклор текстлары, публицистик әсәрләрдән) файдалану аша гамәлгә ашырыла. Мәдәни юнәлеш этномәдәни тәңгәллек (идентичность) формалаштыруга, гражданлык һәм ватанпәрвәрлек хисләре, туган тел белән кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләүгә ярдәм итә. Укучыларны милли мәдәният белән таныштырганда, аны башка халыклар мәдәнияте белән нәрсә берләштерүенә аерым игътибар бирергә кирәк.

Социомәдәни юнәлеш. Әлеге юнәлеш нигезендә, телгә өйрәтү өйрәнелә торган телнең илен һәм мәдәниятен өйрәнү белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.

СӨЙЛӘМ КОМПЕТЕНЦИЯСЕН ҮСТЕРҮ ҺӘМ БУ ЮНӘЛЕШТӘ ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ РОЛЕ

Хәзерге вакытта туган телгә өйрәтү эчтәлеге ике төп юнәлеш белән билгеләнә:

1) традицион (лингвистик төшенчәләр, орфографик күнекмәләр, грамматиканы үзләштерү);

2) коммуникатив (телгә гамәли өйрәнүне тәэмин итә торган сөйләм күнекмәләрен формалаштыру).

Практика күрсәткәнчә, туган телдә белем бирүче оешмалар өчен төзелгән программаларда һәм туган тел дәреслекләрендә лингвистик материал өстенлек итә. Коммуникатив эчтәлек, нигездә, «Туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле» предметын өйрәнүче укучылар өчен төзелгән эш программаларында һәм дәреслекләрдә күзәтелә.

«Туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле» предметының эчтәлеге Россия Федерациясе субъектларының төбәк һәм этнокультура үзенчәлекләрен чагылдырырга һәм белем алучыларның коммуникатив компетенцияләрен булдыруны тиешле күләмдә тәэмин итәргә тиеш.

Мәктәпләрдә «Туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле» предметын укытуның максатлары: 1) укучыларның лингвистик белемгә ия булуын тәэмин итү, ягъни татар теленең фонетик, лексик, грамматик күренешләрен практик үзләштерүгә ирешү; 2) укучыларда коммуникатив

компетенция (фикерне төпле, нигезле итеп белдерү осталыгы) формалаштыру, ягъни телне аралашу, сөйләшү-аңлашу чарасы буларак өйрәтү.

Дидактик материал — укучының танып-белү эшчәнлеген активлаштыручы, аны уку процессына җәлеп итәргә, мәгълүматны кабул итәргә, бирелгән тема буенча уйларга этәрүче материал. Дидактик материал — уку материалының үзенчәлекле төре: карта, таблицалар, текст, тестлар, карточкалар җыелмасы, шул исәптән дәресләрдә һәм өйдә мөстәкыйль эшләү өчен укучыларга бирелә торган яки бөтен сыйныф (төркем) каршында күрсәтелә торган мәгълүмати технологияләр базасында ясалган материаллар.

Дәрес эшчәнлегендә дидактик материалны куллану укучыларның белем алу эшчәнлеген активлаштырырга, уку вакытын экономияләргә ярдәм итә. Димәк, дидактик материал телне өйрәнү өчен өстәмә уку материалы булып тора, телгә өйрәтүне мавыктыргыч, кызыклы, төрле яклы итеп оештыру чарасы буларак хезмәт итә.

Белем бирүдә дидактик материаллар куллану максатлары:

— материалны мөстәкыйль үзләштерү һәм төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләргә өйрәтү;

— танып-белү эшчәнлекләрен активлаштыру;

— яңа материалны мөстәкыйль рәвештә аңлый һәм үзләштерә алуны оештыру;

— үзконтроль һәм үзкоррекция;

— уку материалын үзләштерү процессында күнегүләр эшләү;

— уку вакытын экономияләү;

– укуга мотивация булдыру;

– фикерләү сәләтен үстерү (теоретик, логик, иҗади, абстракт);

– укыту эшчәнлеге культурасын формалаштыру;

– тикшеренү (иҗади) уку мәсьәләләрен бергәләп хәл иткәндә, интеллектуаль һәм эмоциональ функцияләр бәйләнешен активлаштыру.

Дидактик биремнәр төрле дидактик максатлардан чыгып, берничә төргә бүленә:

– танып-белү максаты буенча (мәгълүмат эзләү, материалны истә калдыру, белем-күнекмәләрне куллану, гомумиләштерү, чагыштыру, анализлау һ.б.);

– эчтәлек буенча (репродуктив, эвристик, проблемалы, тикшеренү, компетентлы);

– башкарылу урыны буенча (сыйныфта һәм өйдә);

– укучыларга җиткерү формасы буенча: вербаль, язма, электрон;

– башкару вакыты буенча (кыска сроклы, уртача сроклы һәм озак сроклы);

– башкаручылар саны буенча (индивидуаль, парлы, төркемле).

Моннан тыш, традицион (репродуктив) һәм продуктив биремнәрне аерып карау мөһим. Репродуктив биремнәр: билгеләмәне өйрән, укы һәм эчтәлеген сөйлә, шигырьне яттан өйрән, мәсьәләне чиш, төшеп калган хәрефләрне куеп, күчереп яз, параграфтан соң сорауларга җавап бир, инша яз һ.б. Репродуктив биремнәрнең нәтиҗәсе (яки сорауга җавап) дәреслектә бар, биремне үтәү өчен мәгълүмат тиз табыла, алар предмет буенча

белем һәм күнекмәләр системасы булдыруга юнәлдерелгән. Репродуктив биремнәрне эшләп, укучы теманы кабатлый һәм үзләштерә.

Продуктив биремнәрнең нәтиҗәсе (яки сорауга җавап) дәреслектә әзер килеш бирелмәгән, ләкин текстта һәм иллюстратив материалларда аларны башкарырга ярдәм итә торган күрсәтмәләр бар. Укучы продуктив биремнәрне башкарып чыгу өчен булган белемнәренә һәм тормыш тәҗрибәсенә нигезләнергә тиеш була. Продуктив биремнәр предмет нәтиҗәләрен генә түгел, метапредмет нәтиҗәләрен формалаштырырга ярдәм итә, предметара бәйләнеш булдыра. Продуктив биремнәр укучыларны мәгълүматны табарга, системалаштырырга, анализларга, үзгәртергә, реаль тормыш ситуациясен өйрәнелгән кагыйдәләр һәм закончалыклар белән бәйләргә өйрәтә. Продуктив биремнәр: үрнәк белән чагыштырыгыз, башка вариант тәкъдим итегез, хата табыгыз һ.б.

Дәрес һәм өй эше өчен дидактик бирем сайланганда, дәреснең максатлары, эчтәлеге, укучыларның белем дәрәҗәсе, белемне кабул итә алу мөмкинлекләре, фикерләү сәләтеләре исәпкә алына.

Дидактик материал буларак кулланыла торган чаралар:

— күрсәтмә материаллар: плакатлар, иллюстрацияләр, портретлар, дәреслекләргә кушымталар;

— таратма материаллар: текстлар, күнегүләр, биремнәр язылган карточкалар;

— таблицалар, схемалар, графиклар, диаграммалар;

— уеннар;

— электрон кулланмалар: видео-дәресләр, презентацияләр, электрон аудио- һәм видео китаплар;

— белешмә материаллар;

— яңа материалны өйрәнүнең логик схемасын һәм кирәкле уку-укыту ысуллары чагылдыручы инструктив карточкалар;

— биремне үтәү алгоритмы.

«ТУГАН ТЕЛ һӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ» ПРЕДМЕТЫН ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАРГА ЛЕКСИКОЛОГИЯНЕ ӨЙРӘТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Лексиколо́гия (грекча λέξις — «сүз, аңлатма», λόγος — «укыйм») — тел гыйлеменең сүзлек составын, аның үсеш-үзгәрешләрен өйрәнә торган фән. Лексика — телнең сүзлек составы. Телне белү — аның лексикасын һәм структурасын белү дигән сүз. Лексика, тел аспекты буларак, телнең башка аспектлары — фонетика, грамматика, орфография белән бәйләнгән. Теләсә нинди тел күренешенә өйрәткәндә без сүзләр белән эш итәбез.

Рус телле аудиториядә лексикны өйрәтү телне өйрәтү системасында иң мөһим компонентларның берсе булып тора, чөнки аннан башка сөйләм эшчәнлеген: тыңлап аңлау, сөйләшү, уку һәм язу мөмкин түгел. Шуңа бәйле рәвештә лексик материалны методик яктан грамоталы итеп бирү белемнәрне уңышлы үзләштерергә булыша, ә дидактик материалларның төрлелеге белем бирү процессын тагын да мавыктыргыч итәргә шартлар тудыра.

Лексиканы белү продуктив (телдән, язма сөйләм) һәм рецептив (тыңлап аңлау, уку) сөйләм эшчәнлеген башкару өчен кирәк. Продуктив сөйләм эшчәнлеге — аралашу ситуацияләре һәм коммуникав максатлар нигезендә телдән һәм язма сөйләмдә сүзләрне дөрес куллану күнекмәләре. Рецептив лексик күнекмәләр — тыңлап

аңлау һәм уку вакытында лексик берәмлекләрне тану һәм аңлау күнекмәләре.Татар лексикасын үзләштерүдә продуктив эшчәнлек төрләре формалашсын өчен, рус телле балаларда өйрәнелә торган лексика кысаларында лексик-мәгънәви һәм лексик-тематик ассоциацияләр табу, яңа сүзләрне өйрәнгән сүзләр белән бәйли белү, синонимнар һәм антонимнар арасыннан кирәкле сүзне сайлый алу, сүзләрне, сөйләм ситуациясен исәпкә алып, дөрес куллана белү күнекмәләре формалаштыру зарур. Эшчәнлекнең рецептив төрләре өчен укучыларда түбәндәге күнекмәләрне булдыру кирәк: яңгырашы һәм формасы буенча охшаш сүзләрне аера белү, сүзләрнең мәгънәсен аңлау өчен аның ясалышына игътибар итү, тексттан чыгып сүзләрнең мәгънәсен аңлау.

Татар теле дәресләрендә рус телле укучылар предмет буенча эш программасында билгеләнгән **лексик минимумны** үзләштерергә, хәтердә калдырырга һәм сөйләмдә куллана белергә тиеш. Лексик минимум — укучының билгеле бер вакыт аралыгында үзләштерергә тиеш булган сүзләр җыелмасы. Аның күләме уку вакытының мөмкинлекләре күзлегеннән караганда максималь һәм тел системасы күзлегеннән караганда кечкенә. Һәр уку елында үзләштерергә тиешле лексик минимумның **күләме** предмет буенча федераль эш программаларының «Белем бирү эчтәлеге» бүлегендә билгеләнә. Мәсәлән, башлангыч гомуми белем бирү федераль эш программасының эчтәлек өлешендә 1 сыйныф укучылары 100 дән дә ким булмаган лексик берәмлекне (сүзләрне, сүзтезмәләрне, сөйләм клишеларын) таный һәм куллана белергә, билгеле сөйләм

эчтәлеге(темалар) кысаларында аралашу ситуациясе өчен кирәк булган предмет, билге, хәрәкәт атамаларын, алынма сүзләрне белергә тиеш дип ассызыклана. Алдагы сыйныфларда лексик минимумның күләме 100 сүзгә арта бара, мәсәлән: 2 сыйныфта — 200 сүз, 3 сыйныфта — 300 сүз һ.б.Укытучы дәрес темасы буенча лексик минимумның **тематикасын** татар теле дәреслекләре авторлары тарафыннан төзелгән авторлык программаларына һәм УМКның «Укытучы китабы»на нигезләнеп сайлый. Лексик минимум берничә критерийга туры килергә тиеш:

1) сүзләрнең киң кулланышта булуы;

2) стилистик нейтральлек;

3) сүзнең өйрәнелә торган тема кысаларында кулланылуы;

4) семантик төркемгә кергән сүзләрнең балаларның коммуникатив ихтыяҗына туры килүе.

5) сүзнең алдагы дәресләрдә өйрәнелә торган сүзләр белән бәйләнешкә керә алуы (сүзтезмәләр, җөмләләр төзи алу).

Димәк, лексик минимумны сайлап алу телне белү дәрәҗәсе белән дә, укучыларның яшь үзенчәлекләре, аларның аралашу, кызыксыну сфералары белән дә билгеләнә.

Рус телле аудиториядә татар теленең лексикасын өйрәткәндә, татар теле лексикологиясенең түбәндәге үзенчәлекләренә игътибарлы булырга кирәк:

1.Татар теле лексикасы актив һәм пассив лексикадан тора. Актив сүзләргә көндәлек тормышта һәрдаим кулланыла торган сүзләр керә: су, икмәк, эш, зур, өй, кул, ашау һ.б. Пассив сүзләр — сирәк кулланышлы сүзләр. Рус

телле балаларны укытканда, пассив сүзләрне өйрәтү белән мавыгырга ярамый.

2.Татар телендә сингармонизм законына буйсынмаган гарәп һәм фарсы алынмалары катламы шактый зур (китап, каләм, дөнья, икътисад, имтихан, галим).

3.Татар телендә сүзләр туры һәм күчерелмә мәгънәле була (яшел алма — күз алмасы, чыршы энәсе — тегү энәсе, кыңгырау чәчәге — кыңгырау шалтырады, балык тәңкәсе — тәңкәләр чылтырый; кеше борыны — көймә борыны; кара күлмәк, кара урман, кара кайгы).

4.Лексик интерференция — татар сүзе белән рус сүзе мәгънәләре арасында аерма булу. Мәсәлән, *я иду домой* татарчага, *мин өйгә кайтам* дип тәрҗемә ителергә тиеш. Ләкин еш кына аны рус балалары *мин өйгә барам* дип тәрҗемә итәләр.

Татар һәм рус телләрендә кайбер сүзләрнең уртак булуы телне өйрәнүдә җиңеллек тудыра.

1.Төрки телләрдән рус теленә кергән алынмалар: башмак, хан, кремль,базар, бакалея, гер, ярлык, тамга, кузов, чемодан, тун, халат, карман, башмак, фата, шаровар, бәрән, ишәк һ.б.

2.Рус теленнән татар теленә фонетик үзгәрешләр белән кергән сүзләр: өстәл, бүрәнә, салам, эшләпә, кәбестә, сандык, фатир, мич, кесәл һ.б.

3.Рус теле аша Европа телләреннән кергән сүзләр: армия, грамматика, король, император, химия, физика, кафедра, компьютер, лизинг, бейсбол, маркетинг, менеджер, принтер һ.б.

Татар сүзләренең күпчелеген бер тамырдан ясалган сүзләр тәшкил итә. Агглютинатив тел буларак тамыр үзгәрми: яңа сүз ясалса да, сүзнең формасы үзгәрсә дә, сүзнең тамыры сакланып кала. Мәсәлән: баш, башлык, башмак, башлану, башта, башлы, башка-баш, башлангыч, башак һ.б. сүзләрнең мәгънәләрендәге уртаклыкны эзләп табып була. Бу — баш сүзе, ул һәрвакыт голова, начало мәгънәләре белән бәйле. Димәк, рус укучысы *баш* дигән сүзне истә калдырса, шул тамырны күргәч (ишеткәч), аның мәгънәсен аңлый ала.

РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ ЛЕКСИКОЛОГИЯ БУЕНЧА ДИДАКТИК БИРЕМНӘР

Яңа сүзләрне һәм сүзтезмәләрне өйрәнгәндә хәтернең барлык төрләре эшкә җигелә, шуңа күрә укучыларны яңа лексик берәмлекләр белән таныштыру гына аз, аларның мәгънәсен төрле сөйләм үрнәкләрендә һәм ситуацияләрдә күрсәтергә, сүзне (сүзтезмәне) сөйләмдә куллану күнекмәләре булдырырга кирәк. Лексик берәмлекләрне үзләштерү буенча уку эшчәнлеге өч этапта башкарыла:

1) яңа материал белән таныштыру (сүзләрне, сүзтезмәләрне кертү һәм мәгънәләрен аңлату);

2) лексик берәмлекләрне куллану буенча күнегүләр (беренчел ныгыту);

3) лексик берәмлекләрне куллану (сүзләрне актив сөйләмгә кертү).

Укучыларга яңа сүзләр өйрәтү, алар турында беренчел аңлатма бирү — лексиканы өйрәтү юнәлешендә башлангыч адым. Алга таба сүзләрне үзләштерү һәм сөйләмдә актив куллану күнекмәсе булдыру өчен төрле коммуникатив биремнәр кулланыла. Бу күнегүләр лексик берәмлекләрне хәтердә калдырырга ярдәм итәләр, телдәге башка сүзләр белән бәйләнешен һәм укучыларның туган телендәге эквивалентлары белән мөнәсәбәтен ачыкларга булышалар.

Яңа лексиканы тәкъдим итү, лексик берәмлекнең мәгънәсен аңлату алымнары:

— күрсәтмәлелек (предметларны, хәрәкәтләрне, сурәтләрне күрсәтеп бирү; мимика, жестлар);

— сүзне рус телендәге эквиваленты белән тәрҗемә итү;

— сүзнең мәгънәсен рус телендә аңлату;

— сүзне контекстта күрсәтү яисә билгеле ситуациягә бәйле кулланылышын ассызыклау;

— сүзнең лексик системасында әлеге сүзгә бәйләнешләр табу (синонимнарны куллану: зур, бөек; антонимнар табу: югары — түбән; тема белән бәйле башка сүзләрне атау: яшелчәләр — кишер, суган, кәбестә; тамырдаш сүзләрне искә төшерү: күз, күзлек, күзлекле);

— сүзнең ясалышына игътибар итү (күзлекле — ясалма сүз, күз — тамыры, лек, ле — сүзъясагыч кушымчалар;

— сүзнең төп семантик өлешләрне санап чыгу: чәнечке — ул предмет; азык куллану өчен билгеләнгән предмет һ.б.

Лексик берәмлекләрне куллану буенча күнегүләр (беренчел нығыту):

— текстта сүзне табу, мәсәлән: текстта сүз ничә тапкыр очравын билгеләтү;

— тексттан темага караган сүзләрне күчереп алу;

— сайлап алу биремнәре: «Исемлектән артык сүзне сызыгыз» һ.б.;

— сүзләрне төрле лексик һәм грамматик комбинацияләрдә куллану, мәсәлән: сүзгә синоним (антоним, омоним) табу; сүз белән сүзтезмә (җөмлә) төзү;

сүзнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуына мисаллар китерү һ.б.;

– сүзләрне төрле төркемнәргә аеру, мәсәлән: исем һәм сыйфат сүз төркеменә кергән сүзләрне аерып язу; «җәй» һәм «кыш» темасына караган сүзләрне аерып язу һ.б.;

– сүзләрне билгеле бер тәртиптә урнаштыру.

Лексик берәмлекләрне куллану этабында сүзләрне актив сөйләмгә кертү, иркен куллану өчен төрле дидактик биремнәр эшләтү, өйрәнелгән лексик материалны үзләштерү контроле оештырыла. Дидактик материалның максаты: укучыларның телне өйрәнүгә кызыксынуын арттыру, эшчәнлеген активлаштыру, актив сүз запасын үстерү.Әлеге этапта текст белән эшләү, лексик уеннар, тестлар, коммуникатив биремнәр - сүзләрне өйрәнү һәм актив сөйләмдә ныгыту юлында максатчан эш төрләре булып тора.

Текст белән эшләүне оештыруда төп шартларның берсе — дөрес текст сайлау. Уңышлы тәкъдим ителгән текст укучыларның тел эшчәнлеген максималь рәвештә стимуллаштыра һәм аларны белем алу эшчәнлегенә этәрә. Текст аңлаешлы, актуаль, яңа, кызыклы мәгълүматка ия булырга, укучыларның белем дәрәҗәсенә һәм кызыксыну сфераларына туры килергә тиеш. Текст буенча эш текстны уку, текст буенча эшләү күнегүләрен үз эченә ала: текст буенча сорауларга җавап бирү, эчтәлеген сөйләү, ахырын уйлап язу; темасын, микротемаларын билгеләү; планын төзү, конспектлау, аннотация язу, анализлау һ.б. Текст белән эш оештырылганнан соң текст буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгу оештырыла: телдән

һәм язма, монологик (хикәяләү, тасвирлау, фикерләү) һәм диалогик сөйләм төзү эшчәнлеге башкарыла.

Текстта укучыларга таныш сүзләр, фразалар белән бергә үзләштерү өчен яңа лексик берәмлекләрнең дә булуы зарур. Укучылар тексттагы таныш булмаган сүзләрне аерып алалар, мәгънәсенә төшенәләр, җөмләдә кулланылышына игътибар итәләр. Бу эшчәнлек яңа сүзләрне алга таба актив сөйләмгә кертеп җибәрү өчен төпле җирлек булып хезмәт итә.

Диалог — ике кеше арасында бара торган сөйләм. Дәрестә оештырылган диалогик сөйләм барышында вакытында ике укучы арасында мәгълүмат алмашу оештырыла. Диалогта катнашучылар бер-берсенә чиратлап сорау/җавап, раслау/инкяр итү, шик белдерү, ышанмау, риза булу/риза булмау, үтенү, киңәш бирү формаларында репликалар әйтәләр, шулар аркылы татар теленең аерым грамматик формаларын өйрәнү, сүзлек запасын тулыландыру, дөрес әйтелеш нормаларын үзләштерү тормышка ашырыла. Укучыларны диалогик сөйләмгә өйрәтү күнегүләре күптөрлелеге һәм кызыклы булуы белән аерылып тора. Алар укучыларга белемнәрен кабатларга, аларның интеллектуаль фикерләвен, коммуникатив сәләтен үстерергә ярдәм итә.

Диалогны тулыландыру.

Укучылар бирелгән диалогка репликалар өстәп укыйлар.

– Сәлам, Айнур!
– ...
– Кая барасың?
– ...

– Нәрсә аласың?
– ...

Диалогны дәвам итү.

Укучылар бирелгән диалогны дәвам итәләр һәм иптәшләре белән сөйләшү үткәрәләр.

– Исәнмесез, Алсу апа!
– Исәнме, Марат!
– Алсу апа, мина дәфтәрләр кирәк.
– ...?
– ...

Диалогны тәмамлау.

Укучылар диалогның ахырын уйлап бетерәләр һәм сыйныфташлары белән сөйләшәләр:

– Син әниеңә булышасыңмы?
– Әйе, булышам.
– Ничек булышасың?
– ...

Диалогта дөрес кулланылмаган сүзләрне табу.

– Походка нәрсә алалар?
– Походка палаткалар, йокы капчыклары, кармак, аптечка, утюг һәм кул фонаре алалар.
– Походка нәрсә киеп баралар?
– Походка концерт киемнәре, уңайлы аяк киеме киеп баралар.
– Балыкны кайда тоталар?
– Балыкны тауда тоталар.
– Балыкны нәрсә белән тоталар?

– Балыкны таяк белән тоталар.
– Походка баргач, кайда йоклыйлар?
– Походка баргач, агач өстендә йоклыйлар.

Ачкыч: : компас, спорт, елгада, кармак, палаткада.

Текстка нигезләнеп диалог төзү.

Минем этем бар. Аның исеме – Актүш. Актүш өйдә яши. Ул бик матур, акыллы. Ул безнең белән уйный.

– Синең этең бармы?
– Әйе. Минем этем бар.
– Аның исеме ничек?
– Аның исеме — Актүш.
– Ул нинди?
– Ул матур, акыллы эт.

Раслау (инкарь итү/сорау/ каршы килү/ киңәш бирү/үтенү һ.б.) репликасы булган диалог төзү.

– Алсу, син өйдәме?
– Әйе, мин өйдә.
– Нишлисең?
– Китап укыйм.
– Нинди китап?
– Бик кызыклы китап. Син дә бу китапны укып чык!

Диалогны җавап-репликалар белән тулыландыру өчен дөрес җавап-репликаны сайлап алу.

– 1. Син җәй көне походка барасыңмы?
– А. Әйе, барам. Б. Бүген һава торышы яхшы.
– 2. Походка кем белән барасың?
– А. Песием белән.Б. Әтием белән.

– 3. Походка кая барасың?
– А. Елга буена. Б. Әбиләргә кунакка.
– 4. Походта кайда төн кунасың?
– А. Көймәдә. Б. Палаткада.
– 5. Учак яга беләсеңме?
– А. Бүген һава торышы начар.Б. Юк, ләкин миңа әтием өйрәтә.
– 6. Учакта нәрсә пешерәсең?
– А.Балык ашы. Б. Бәлеш.

Укучылар диалог төзегәндә, яңа сүзләрне кулланалар, мәгънәләрен истә калдыралар, лексик берәмлекләрнең иң кирәклесен сайлап алалар, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясыйлар. Әлеге төр эшчәнлек вакытында балаларның интеллектуаль фикерләү һәм коммуникатив осталыклары үсеш ала. Диалог аша укучылар татар сөйләм этикеты үрнәкләрен, тотрыклы сөйләм гыйбарәләрен, төрле репликаларны актив үзләштерәләр. Уку аралашуы көндәлек аралашуга күчсен өчен, балаларның үз фикерләрен төгәл һәм дөрес итеп белдерергә өйрәтү зарур.

Дәрестә *лексик уеннар* укучыларның игътибарын лексик материалга юнәлтүгә һәм сүзлек запасын киңәйтүгә хезмәт итә, аралашу ситуацияләрендә сүзләрне дөрес, урынлы куллануны тәэмин итә. Татар телен дәүләт теле буларак укыту дәресләрендә уен куллануның күпъеллык практикасы телне өйрәнгәндә уен технологиясенең отышлы булуын раслый.

Дәрескә уен керткәндә, аның исәпкә алынырга тиешле үзенчәлекләре бар:

1) уен дидактика күзлегеннән чыгып төзелергә, укучыларның белем дәрәҗәсенә туры килергә тиеш;

2) дәрестә уен эшчәнлеге мотивлаштырылган булырга, ә укучыларда аңа ихтыяҗ булырга тиеш;

3) уенда катнашуга укучыларның психологик һәм интеллектуаль әзерлеге зур роль уйный. Уен күтәренке кәеф булдыруга, дустанә мөнәсәбәт урнаштыруга, үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек атмосферасында аралашуга ярдәм итәргә тиеш;

4) укытучы укучыларның индивидуаль үзенчәлекләрен — һәр катнашучының холкын, темпераментын, максатчанлыгын, тырышлыгын, оешканлыгын, тәртибен, ихтыярын, сәламәтлегенең торышын, кәефен исәпкә алырга тиеш;

5) уен төрле дәресләрдә алынган коммуникатив универсаль уку гамәлләренә таянырга, укучыларның рациональ һәм нәтиҗәле карарлар кабул итү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шул ук вакытта үз-үзләрен һәм әйләнә-тирәдәгеләрне объектив бәяли белергә өйрәтергә тиеш.

Уен төрләре. Уеннар уку максатлары һәм бурычлары, үткәрү формасы, оештыру ысулы, катлаулылык дәрәҗәсе, катнашучыларның саны буенча аерымлана.

Уенда катнашучыларның саны буенча индивидуаль, парлы, төркемле, коллектив уеннар була.

Уенны оештыру ысулы буенча компьютер, имитация-модельләштерү, язма, телдән, хәрәкәтле була.

Башкарыла торган гамәлләрнең катлаулылыгы буенча гади һәм катлаулы уеннарны аерып карыйлар.

Үткәрү характеры һәм формасы буенча вербаль, хәрәкәтчән, сюжетлы, интеллектуаль (ребуслар, кроссвордлар, чайнвордлар, башваткычлар һ.б.), үзара аралашу (коммуникатив) һәм рольле уеннар,эшлекле уеннар аерылып чыга.

Уеннар өйрәтү максатлары һәм бурычлары буенча телгә өйрәтү һәм сөйләмгә өйрәтү (коммуникатив) төрләренә бүленәләр. Коммуникатив уеннар сүзләрне сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү, грамоталы сөйләм оештыру күнекмәләре булдырырга ярдәм итәләр.

Төрле сыйныфларда гамәли биремнәргә уен элементлары кертеп җибәрү отышлы. Сүзләр белән бәйле күптөрле *тел уеннары* укучыларда кызыксыну уята.

Аерым билгеләр буенча сүзләр табу (беренче аваз, хәреф һәм иҗек буенча; бирелгән тема буенча; рәсем буенча; соңгы хәреф буенча; синонимнар, антонимнар табу).

Сүзләрне тергезү (төшеп калган хәрефләрне кую; таралган хәрефләрне тиешле тәртиптә урнаштыру; таралган сүзләрдән җөмләләр төзү; яңа сүз ясау өчен хәрефләр (иҗекләр) өстәү яки алып ташлау).

Сүз эченнән яңа сүзләр табу. Мәсәлән, *нарат* сүзендә *ат, тар, ант, ара, ана, тана* кебек сүзләр яшеренгән.

«Тирәбездә нәрсәләр бар?» уены (мөмкин кадәр күбрәк әйләнә-тирәдәге әйберләрнең исемнәрен атау).

«Кем яхшы күрә?» (рәсемнәрдә сурәтләнгән әйберләрне, аларның билгеләрен, хәрәкәтләрен санау).

«Нинди сүз җитми?». Тактага сүзләр яки сүзтезмәләр языла. Укытучы укучыларга күзләрен йомарга куша һәм шул вакытта бер сүзне сөртә. Укучылар нинди сүз яки

сүзтезмәнең җитмәвен һәм аны тактада ничек дөрес итеп язарга икәнен аңлатырга тиеш.

«Сүзләр чылбыры». Тактага сүзтезмә языла, мәсәлән: «тәмле алма». Беренче укучы «тәмле» сыйфатын алмаштырырга тиеш: «кызыл алма», икенче укучы исә, сүзтезмәдә исемне алмаштыра, мәсәлән: «кызыл күлмәк» һ.б. Кирәкле сүз таба алмаган укучы уеннан чыга, ә чылбырны башка катнашучы дәвам итә. Уен бер җиңүче калганчы дәвам итә.

«Кар өреме». Укучылар бер-берсенә туп ыргыталар. Биремнәр төрле булырга мөмкин:

а) сүзләрне русчадан татар теленә тәрҗемә итү һәм киресенчә;

б) әйтелгән сүз белән сүзтезмә яки гади җөмлә төзү;

в) сүзнең антонимын (синонимын) табу һ.б.

«Соңгы хәреф». Уенны индивидуаль һәм төркемләп уйнарга була. Беренче командадагы укучылар тема буенча сүз әйтә, икенче команда шул сүзнең соңгы хәрефенә (иҗегенә) башланган сүз уйлый, беренче команда икенче сүзнең соңгы хәрефенә өченче сүзне уйлап табарга тиеш. Соңгы сүзне әйткән команда җиңә.

*«Төсләр».*Уенның бурычы — бер төстәге предметларны атау. Мәсәлән: яшел — күлмәк, үсемлек, каен, күз, үлән, алма һ.б. Күбрәк предметларны атый алган укучы яки команда җиңүче була.

Шулай ук шарадалар, ребуслар, кроссвордлар, сканвордлар чишү автомат рәвештә яңа сүзләрне һәм аларның мәгънәләрен искә төшерергә ярдәм итә.

Коммуникатив уеннар сөйләм актын (монологик һәм диалогик, язмача һәм телдән) үтәү процессында тел чараларыннан дөрес файдаланырга өйрәтәләр.

«Кәеф ничек?» — укучы үзенең кәефенә туры килә торган смайликлы рәсемне сайлап, кәефе турында бәян итә.

«Бу кем?» — сыйныфташны яки берәр танылган кешене тасвирлау (тышкы кыяфәте, характеры, мавыгулары, гамәлләре һ.б.). Башка укучылар кем турында сүз баруын ачыкларга тиешләр.

«Мин кем?» – укытучы укучы аркасына бер сүз язылган табличка элә (мәсәлән: син — блогер, син — рәссам, син — язучы). Укучы сораулар ярдәмендә үзенең кем икәнен ачыкларга тырыша. «Әйе», «юк» дип җавап бирә торган сораулар булырга тиеш.

«Портрет».Укытучы укучыларга таныш булмаган кешеләрнең рәсемнәрен/фотографияләрен тарата. Шул рәсемнәргә карап, укучылар бу кеше турында мәгълүмат бирергә тиеш: исеме, яше, профессиясе, кайда яшәве, мавыгулары, гаиләсе, тышкы сыйфатлары, шәхси сыйфатлары.

«Понтамимо».Укытучы дәрес темасына караган сүзтезмәләр язылган карточкалар тарата. Укучылар, берәм-берәм чыгып, карточкада язылган сүзтезмәне понтамимо итеп күрсәтәләр, калганнар сүзтезмәне атарга тиешләр.

«Кем күбрәк» — сыйныфта укучылар ике командага бүленә. Алып баручы сүз тәкъдим итә, мәсәлән, *йомшак*. Командалар билгеле вакыт аралыгында шул сүз белән күбрәк сүзтезмәләр, я кыска җөмләләр уйлап табарга

тиеш. Күбрәк уйлап табучы команда җиңүче була. Урта сыйныфларда билгеле бер тема буенча шул сүзне максималь кулланып, кыска гына хикәя төзетергә була. Мисал: «*Урамда кыш, көн аяз, һава йомшак. Тыныч кына йомшак кар ява. Балалар йомшак бияләйләрен киеп урамга чыктылар һәм йомшак кар атышып уйный башладылар. Бервакыт әнинең йомшак тавышы ишетелде...*».

«*Парыңны тап!*» – сыйныфта һәр ике укучы бер шәһәргә сәяхәткә җыена. Укучылар бер-берсенә сораулар биреп, үзләре кебек бер шәһәргә бара торган парын эзләп табарга тиеш.

«*Күлмәк*» – укучы тактага күлмәк рәсемен ясый һәм шуның эченә төрле сүзләр, саннар (туган көн датасы, туган/яшәгән шәһәр, яраткан шөгыль, төс, кием, мәктәп фәне, йорт хайваны һ.б.) яза. Калган укучылар аңа төрле сораулар биреп, бу сүзләрнең һәм саннарның нәрсә аңлатканын белергә тиеш. Дөрес сорау биргән һәм җавап тапкан укучыларга яшел карточкалар бирергә мөмкин. Кемдә күбрәк карточка җыела, шул җиңүче була.

«*Лото*». Укучыларга татарча җөмләләр язылган карточкалар таратыла. Җөмләләр хәрәкәтне белдерә торган фигыльләрне ныгытуга юнәлдерелгән. Алып баручы капчыктан бер хәрәкәт сурәтләгән рәсемне ала һәм укучыларга күрсәтә. Катнашучыларның бурычы — карточкалардан рәсемгә туры килә торган җөмләне табу һәм аны фишка белән каплау. Барлык җөмләләрне беренче каплап бетерүче җиңүче була.

«*Үстерешле канун* — өч сүз әйтелә, шуларның беренче икесе үзара мөнәсәбәттә тора, өченче сүзгә шундый ук мөнәсәбәттә торган дүртенче сүз табыла. Мәсәлән: Каен —

агач, шигырь — ..., сыйфат — сүз төркеме, аергыч — җөмлә кисәге, йорт — төзүче, хикәя — язучы һ.б. Үрнәкләр:

Дүшәмбе — беренче, җомга — _____.

Каен — яфраклы, чыршы — _____ .

Лимон — әче, шикәр — _____.

«Капкын» – укытучы дәрес темасы буенча бер сүзне тыелган сүз итеп сайлый һәм такта янына чыккан ике катнашучыга бу сүзне башкаларга ишетелмәслек итеп әйтә. Бу ике укучы кулларын тотышып, «капкын» ясыйлар. Калган укучылар чиратлап чыгып, «капкын» янына киләләр һәм тема буенча берәр сүз әйтәләр. Әгәр бер укучы тыелган сүзне әйтә икән, ул «капкын»га эләгә. Алга таба уенны башка тыелган сүз сайлап дәвам итеп була. Уен соңгы укучыга кадәр дәвам итә.

«Ассоциатив рәт» – өйрәнелә торган тема тудырган ассоциацияләрне атау (төшенчәләр, образлар, идеяләр, фразалар, истәлекләр, хисләр һ.б.). Сүзләр билгеле тематикага берләштереп, таблицага тутырыла. Үрнәкләр:

КЫШ		
Исемнәр	Сыйфатлар	Фигыльләр
Чана	салкын	туңу
боз	бозлы	шуу
кар	якты	кар атышу
Кыш бабай	карлы	кар көрәү

ҖӘЙ		
Шөгыльләр	Кием-салым	һава торышы
Йөзү	күлмәк	аяз
Җиләк җыю	эшләпә	кояшлы
Кызыну	футболка	эссе

Алга таба сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзетергә, кечкенә хикәяләр яздырырга була.

«Минем ассоциация» — укытучы балалар белгән бер яки берничә сүз әйтә. Укучыларның бурычы — билгеле бер вакыт аралыгында бу сүзләргә татарча ассоциацияләр язарга. Иң күп ассоциация тапкан укучы җиңүче була. Мәсәлән: *бәйрәм – туган көн, Яңа ел, Җиңү бәйрәме, торт, кунаклар, шарлар, чәчәкләр, бүләк, табын, концерт* һ.б.

«Ачкыч сүзләр» – укытучы тактага тексттан алып 4-5 ачкыч сүз яза. Укучыларга шушы сүзләрне кулланып, кечкенә хикәя язарга кушыла. Укучылар чыганак текст һәм үз хикәяләрен чагыштыралар.

Рус телле аудиториядә кулланыла торган барлык уеннарның аермалы ягы — аларның коммуникатив юнәлеше булуы. Уенда мәҗбүри төп этапларны аерып күрсәтергә мөмкин: әзерлек, үткәрү, нәтиҗә ясау этаплары.

Әзерлек этабы уенның планын һәм гомуми тасвирламасын бәян итүдән, матди тәэмин ителешне әзерләүдән башлана. Алга таба проблемаларны, максатларны, инструкция, регламент, уен кагыйдәләре, рольләрне бүлү, төркемне формалаштыру оештырыла. Уенның кагыйдәләре аңлаешлы төгәл аңлатылырга тиеш.

Дидактик тест — хәзерге белем бирү системасының иң еш кулланыла торган тикшерү формасы. Тест ярдәмендә укучыларның белемнәрен тикшерү махсус төзелгән тест биремнәре буенча оештырыла. Укыту тестларының максаты — укучыларның аралашу һәм тел компетенцияләренең дәрәҗәсен билгеләү. Тест сораулары берничә вариантта эшләнә. Алардагы биремнәр логик эзлеклелектә, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелә. Укучыларга белем бирү, фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру, тәрбияләү процессында тестлар куллану мәгълүматны кабул итү, игътибарны көчәйтү, хәтер һәм интеллектны үстерүдә югары күрсәткечләргә

ирешергә мөмкинлек бирә, кешенең ми эшчәнлеген, уйлау сәләтен активлаштыра. Дәрестә даими рәвештә тест уздыру укучыларның активлыгын һәм игътибарын үстерә, биремнәрне үтәгәндә, аларның җаваплылыкларын арттыра.

Тестның башка тикшерү формаларыннан түбәндәге өстенлекле яклары бар:

– белем һәм күнекмәләрне үзләштерү сыйфатын тикшерү тизлеген арттыра;

– уку материалын тулысынча кабатларга ярдәм итә;

– контроль нәтиҗәләрен математик-статистик эшкәртү мөмкинлеге барлыкка килә һәм, нәтиҗә буларак, педагогик тикшерүнең объективлыгын арттыра;

– адаптив тестларны куллану ярдәмендә индивидуальләштерү һәм укытуны дифференциацияләү принцибын гамәлгә ашыру мөмкинлеге барлыкка килә.

Алга таба дидактик тест төрләренә үрнәкләр китерелә.

1.Фразеологизмнарны һәм аларның рус эквивалентларын уклар белән бәйләгез.

Җиң сызганып эшләргә	*Навострить уши*
Борын төбендә генә	*Зуб на зуб не попадает*
Колагын торгызу	*Сдержать слово*
Кул селтәү	*Работать засучив рукава*
Баш ватту	*Махнуть рукой*
Теше тешкә тимәү	*Смотреть сквозь пальцы*
Сүзен тоту	*Под носом*
Бармак аша карау	*Ломать голову*

2.

А. Текстны укыгыз. Текстның эчтәлегеннән чыгып, «текстка туры килә», «текстка туры килми» яки «текстта әйтелми» дигән җаваплардың дөрес вариантын сайлагыз.

Матур, кояшлы язгы көн. Кечкенә Фәрит әтисе һәм әнисе белән бакчада. Аның әтисе — бакчачы. Ул

бакчасына помидор, кыяр, шалкан, кәбестә һәм тагын күп яшелчәләр утырта. Менә кәбестә үсентеләре. Әтисе аларны рәт-рәт утырта, әнисе аңа ярдәм итә. Фәрит кечкенә чиләк белән аларга су сибә. Әтисе моңа бик шат.

Фәрит кәбестәләргә көн саен су сибә торган булды. Көндез кәбестәләр кояшка елмаеп карыйлар. Кайбер көннәрдә яңгыр ява. Ә яңгырдан соң кәбестәләр тагын да яшелләнеп, матураеп китә.

Менә көз җитте. Кәбестәләр өлгерде. Уңыш яхшы булды. Әти-әнисе белән бергә Фәрит тә шатланды.

Фәрит әти-әнисе белән ямьсез бер көндә бакчада эшли.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

Яз соң килгән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

Фәритләрнең бакчалары елга буенда урнашкан.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

Әтисе кәбестә үсентеләрен китапта язылганча утырта.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

Яңгыр яугач, үсентеләр тагын да матураеп китә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми 3) текстта әйтелми

Ә. Текстны укыгыз. Әгәр сез әлеге фикер белән килешәсез икән, «+» куегыз, килешмәсәгез, «—» куегыз.

Кыш җитте. Тирә-як ап-ак карга күмелде. Кар җепшек иде. Балалар Кар бабай ясый башладылар. Кечкенә Ира да аларга булышты. Ул өйдән кишер алып чыкты. Кишердән борын ясадылар. Аннан соң күмердән күзләрен ясадылар. Кар бабайның кулына себерке тоттырдылар. Бик кызык кар бабай килеп чыкты.

Кич булды, караңгы төште. Балалар өйләренә кайтып киттеләр. Ира гына китмәде. Ул Кар бабайны кызганды.

– Үзе генә калгач, куркыр, — дип уйлады ул.

– Ира, карны тәгәрәтеп, эт баласы ясады.

– Менә хәзер икәү булдыгыз. Икәү булгач курыкмассыз инде, диде дә эти-әнисе янына өйгә кереп китте.

1) Кыш үтеп бара.

2) Балалар шугалак ясадылар, тимерьякта шуалар.

3) Кар бабайның борынын кишердән, күзләрен күмердән ясадылар.

4) Ира кар бабай өчен борчылды.

5) Малай Кар бабайга иптәшкә эт ясап куйды.

3.

А. Хаталы сүзне табыгыз.

1) бәйрәм
2) төлкө
3) болытлы
4) күңелле

Ә. ***Көнчыгыш*** сүзенә капма-каршы мәгънәле сүзне табыгыз.

1) җылы як
2) көнбатыш
3) төньяк
4) көньяк

Б. ***Ашамлык*** сүзенә охшаш мәгънәле сүзне (синоним) табыгыз.

1) ашханә
2) байлык
3) ашъяулык
4) ризык

В. Мәгънәсе буенча туры килгән сүзне сайлагыз.

Дәүләт гимны ... .

1) балкый
2) хөрмәт итә
3) үсеш ала
4) яңгырый

Г. ***Куян йөрәкле*** фразеологизмын кайсы сүз белән алмаштырып була?

1) тыйнак
2) усал
3) акыллы
4) куркак

Д. Антоним сүзләр рәтен күрсәтегез.

1) бара, ала
2) көлә, елмая
3) каршылый, озата
4) саргая, кызара

Е. Санның дөрес тәрҗемәсен табыгыз. ***Около десяти:***

1) унынчы 2) унлап 3) унышар 4) унау

Ж. Хаталы тәрҗемне табыгыз.

1) кызык — забавный
2) туры — прямой
3) киң — узкий
4) зур — большой

З. Спорт белән шөгыльләнүне белдергән фигыльләр кайсы рәттә урнашкан?

1) укырга, ятларга, утырырга, аңларга
2) ярышырга, йөгерергә, йөзергә, шөгыльләнергә
3) язарга, йокларга, кararга, кызыксынырга

4) сорашырга, йөрергә, шуарга, атларга

И. Артык җөмләне билгеләгез. ***Юл аша чыкканда,*** ...
1) игътибарлы бул.
2) башта — сулга, аннан — уңга кара.
3) башта светофорга карарга кирәк.
4) төшке ашны ашагыз.

4. Һәр юлда артык сүзне сызыгыз.
1) ярдәм, ышанычлы, кешелекле
2) авылдаш, әңгәмәдәш, ватандаш
3) әдәпле, уңган, тупас
4) сәламләү, тәмамлау, исәнләшү.

5.
А. Һәр юлда мәгънәләре буенча туры килә торган фигыльләрне языгыз.
1) Муса Җәлил биш елга якын Казанда_____.
2) Татарстанның бай тарихы музейларда_____.
3) Музей залларында меңләгән экспонат_____.
4) Антарктидадагы иң биек тауларның берсе Муса Җәлил исемен_____.
5) Җәлилне «татар Фучигы» дип_____.
Ачкыч: 1) яшәгән; 2) чагыла (саклана); 3) саклана; 4) йөртә; 5) атыйлар.

Ә. Җөмләне дәвам итеп бетерегез.
1) Кояш чыга һәм ... _____.
2) Дәрес башланды, ләкин ..._____.
3) Диңгезгә карыйм да ..._____.
4) Кемдер шалтыраткан, әмма ... _____.

6. Мәкальләрдә төшеп калган сүзләр урынына антоним сүзләр куегез.

а) Ялкау кеше — яфрактай, _____ кеше — имәндәй.

ә) Кечкенә чишмәләрдән_____ елгалар була.

б) Эше ачы булса, ашы_____булыр.

в) Сүз күп җирдә эш _____була.

г) Бауның озыны, сүзнең _____ яхшы.

д) Хезмәтнең тире ачы булса да, җимеше _____ .

е) Олы өйгә ни кирәк, _____ өйгә шул кирәк.

Ачкыч: эшчән, зур, тәмле, аз, кыскасы, татлы, кечкенә.

7.

А. Җөмләләрне тәрҗемә итегез.

Мою подругу зовут Алсу. — _____.

Ей 17 лет. — _____.

Она студентка. — _____.

Она учится в колледже. — _____.

Она хочет стать дизайнером. — _____.

Она очень талантливая и трудолюбивая. — _____.

Она хороший друг. — _____.

Ей нравится готовить национальные блюда. — _____.

Ә. Диалогны тәрҗемә итегез.

— Илдар, сиңа ничә яшь?

— Биш.

— Ә үзең минем зонтиктан да тәбәнәгрәк.

— Ә сезнең зонтикка ничә яшь соң?

8. Клоуз-тест текстны укып аңлау, төшереп калдырылган берәмлекләрне торгызуны күздә тота. Мондый биремне уңышлы башкару укучының текстны никадәр тиз аңлый алуына һәм анда тасвирланган вакыйгалар яки фактлар арасындагы бәйләнешне билгели алуына турыдан-туры бәйле. Мондый тест өйрәнелә торган телнең лексикасын белү дәрәҗәсен билгели.

Ике төрле үткәреп була.

1. Билгеле бер ешлыкта (мәсәлән, 5 нче, 7 нче h. б.) сүз төшереп калдырыла. Төшереп калдырылган сүз я мөстәкыйль, я ярдәмче сүз төркеменә карарга мөмкин. Тест өчен сайланган текст төзелеше буенча бөтен, мәгънәсе буенча тәмамланган фактларны яки вакыйгаларны бәян итәргә, ә төшеп калдырылган сүзләр контекст хисабына шактый җиңел торгызылырлык булырга тиеш.

Бүген безгә кунак апа ... . Ул миңа матур курчак ... . Курчакның күзләре зәп-зәңгәр, чәчләре ... һәм сап-сары. Күлмәге дә ... матур. Мин кунак апага ... әйттем. Миңа бүләк бик ... .

Безгә дус кызым Оля ... . Оляга да курчак ошады. ... курчакка Алсу исеме бирдек. ... икәү бергә уйнадык. Безгә ... күңелле булды. Иртәгә Оляга ... кунакка керәм. (55 сүз).

Ачкыч: 1 — килде, 2 — бүләк итте, 3 — озын, 4 — бик, 5 — рәхмәт, 6 — ошады, 7 — керде, 8 — без, 9 — без, 10 — бик, 11 — мин.

2. Сүзләрне төшереп калдыру (пропусклар) вариативлык мөмкин булган урыннарда куела. Һәр күнегүдә төшереп калдыруларны сүзләр белән генә түгел, ә сурәтләү чаралары (фразеологик әйтелмәләр, эпитетлар, метафоралар, чагыштырулар һ.б.) белән тутырырга кирәклегенә игътибар итәргә кирәк. Укытучы эш алдыннан укучыларга текстның эчтәлеге турында кыскача мәгълүмат бирә — эш өчен семантик кыр булдыра. Укучыларга оригинал текст күрсәтелми. Монда укучының иҗади эшчәнлеге мөһим. Бары семантик һәм грамматик яктан сүзләрнең урынлы куллануы тикшерелә.

Яхшы кешенең _____ күп була. Һәрвакыт үзен генә кайгырткан, _____кешегә чын _____ табу кыен. Кайберәүләр турында: «Ай, аның _____ күп!» — диләр. Киң күңелле, _____, ярдәмчел кешеләрнең _____ күп була

бит! Андыйлар үз тирәләренә дә _____ кешеләрне җыялар, иптәшләрен үзара таныштырып, якынайтып бетерәләр.

Чын _____үзенә _____ кешенең хаталарын бетерергә тырыша. Ул моны шундый _____ эшли ки, _____ ачуы да килми, күңеле дә рәнҗеми.

Чын дуслык _____ килгәндә сынала. Шатлыкны уртаклашучылар күп булса да, _____ килсә, алар каядыр юкка чыга. Мондый чакта таяныр кешең булу – зур _____.

Ачкыч: 1 — дуслары, 2 — эгоист, 3 — дус (иптәш), 4 — дуслары, 5 — ачык йөзле (акыллы, тарыш һ.б.), 6 — дуслары, 7 — яхшы(акыллы, тәртипле, әдәпле һ.б.), 8 — дус, 9 — якын (кадерле), 10 — оста (сиздермичә), 11 — кешенең (дусның, якын кешенең), 12 — авырлык (кайгы, мәшәкать), 13 — кайгы (авырлык), 14 — бәхет (шатлык, куаныч, сөенеч).

Текст укучылар санына туры китереп әзерләнә һәм таратыла. Укучылар үзлектән текстны ике тапкыр укыйлар. Беренче тапкыр укыганда, алар аның гомуми эчтәлеге белән танышалар, икенчесендә — текстның эчтәлеген торгызу өчен кирәкле сүзләр белән буш урыннарны тутыралар.

Клоуз-тест шулай ук чит телле сөйләмне ишетеп аңлауны тикшерү чарасы да булырга мөмкин. Аудированиене өчен клоуз-тест әзерләгәндә, укучыларга таныш лексик материал һәм гади синтаксик структуралар булган текстны сайлап алырга кирәк.

Клоуз-тестларның сыйфатын бәяләү түбәндәгечә башкарыла. Һәр дөрес җавап өчен укучы 1 балл ала, дөрес булмаган җавап яки җавап булмаган очракта 0 балл куела. Әгәр укучы җавабында таләп ителгән сүзне түгел, ә аңа якын мәгънәле сүзне сайласа, уку яки аудирование күнекмәләрен контрольдә тотканда, ул 1 балл, ә агымдагы контроль эш уздырганда — 0,5 балл ала.

Лексиканы өйрәнү өчен уңышлы сайланган дидактик материал татар теленә өйрәтү, хаталарны кисәтү

һәм төзәтү процессында зур роль уйный. Лексик биремнәр укучыларда уку эшенә уңай, эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыра, бу материалны яхшырак үзләштерүгә ярдәм итә. Гамәли эшләр башкару нәтиҗәсендә, укучыларның мөстәкыйль танып белү эшчәнлеге үсә, бу белем алу сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. «Татарстан республикасы дәүләт теле — татар теле» укыту предметы өчен дидактик материаллар / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г. — Казан: ТРМҮИ, 2022 — 38 б.

2. «Туган тел» предметы буенча дидактик материаллар/ төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р. Ф., — Казан: ТРМҮИ, 2022 — 32 б.

3. 2019/2020 нче уку елында «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәбият (татар әдәбияты)» укытуның актуаль мәсьәләләре/ төз.: Шәмсетдинова Р. Р., Фәттахова Р. Ф., Гыйләҗева Л. Г. — Казан: ТРМҮИ, 2019. — 56 б.

4. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен ТР дәүләт теле буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р.Ф., Хадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2021. — 85 б.

5. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р.Ф., Хадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2020. — 32 б.

6. Гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2021. — 64 б.

7. Җамалетдинова З.И.Татар теле: туган телдә (татар телендә) башл. Гомуми белем бирү оешмаларының 2 нче сыйныфы өчен дәреслек. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013. — 127 б.

8. Имтихан өчен биремнәр (белем бирү эчтәлеге этномәдәни (татар) компонентлы белем бирү оешмаларында туган (татар)телдән имтихан үткәрү өчен методик тәкъдимнәр һәм үрнәк текстлар)/ төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г.— Казан: ТР МҮИ, 2019. — 45 б.

9. Сыйныфтан тыш эшчәнлекне оештыруның бер төре буларак олимпиада хәрәкәте/ төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В.Казан: ТРМҮИ, 2020. — 52 б.

10.Татар теле буенча төп дәүләт имтиханына әзерләнү өчен биремнәр/ төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2020. — 47 б.

11.Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының предмет һәм методика өлкәсендәге компетенцияләрен бәяләү өчен биремнәр/ төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2020. — 47 б.

12.Татар телен һәм әдәбиятын укытуда коммуникатив технологияләр (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 53 б.

13.Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Мөхәрләмова Г.Н., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 55 б.

14.Шамсутдинова Р.Р. Методические рекомендации по подготовке к олимпиадам по татарскому языку русскоязычных учащихся. — ТРМҮИ, 2016. — 36 б.

15.Туган тел (татар телен) һәм әдәбиятны укытуда дәрестән тыш эшчәнлекнең роле / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Гыйләҗева Л.Г., Фәттахова Р.Ф., Хадиева Г.В.. — Казан: ТРМҮИ, 2019 — 40 б.

16.Фаттахова Р.Ф. Практический татарский язык: методическое пособие для изучающих татарский язык. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. — 176 с.

17.Фәттахова Р.Ф. «Белемнәрне системалаштыру һәм гомумиләштерү дәресләре» — Фәнни Татарстан, № 1, 2019. — 109-114 б.

18.Фәттахова Р.Ф. Рус төркемнәрендә татар телен укытуда коммуникатив технологияне куллану. — Сборник материалов Международной НПК «Правовые основы функционирования гос. языков в условиях дву- и многоязычия». — Казань: ИЯЛИ, 2019. —198-200 с.

19.Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2005. — 160 б.

«ТУГАН ТЕЛ һӘМ (ЯКИ) РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ»
УКУ ПРЕДМЕТЫ ӨЧЕН
ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР (ЛЕКСИКОЛОГИЯ)

Техническое редактирование Гиниятуллина Р. С.,
Некратова А. В.
Дизайн обложки Шайхутдинова Д.М.

Форм.бум.60х84 1/16. Усл.п.л. 2,8
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ
420015 Казан, Зур Кызыл ур., 68
Тел.: (843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com

Институт развития образования
Республики Татарстан
420015, Казань, Большая Красная, 68
(843) 236-65-63, 236-62-42
irort2011@gmail.com